РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

№ 105 «11» марта 2019г.

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 елның 20 июнендәге 241 номерлы "Контракт
хезмәтендәге даими составны һәм контракт
идарәчесенең вазыйфаи инструкциясен раслау хакында"
карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 31 декабрендәге 504-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 20 июнендәге 241 номерлы карары белән расланган контракт хезмәте турында регламентка (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Регламентның 20 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

“20. Электрон мәйданчык операторлары, махсуслаштырылган электрон мәйданчык операторлары һәм аларның вазыйфаи затлары сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, граждан-хокукый, административ, җинаять җаваплылыгына тартылылалар, шулай ук хокуксыз гамәлләр (гамәл кылмау) нәтиҗәсендә затларга китерелгән зыянны капларга тиеш, шул исәптән электрон процедураларны үткәрү барышында алынган мәгълүматны тарату буенча да.”

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Нуруллинга Э. Г. йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Йосыпов И.В.